КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 17 сентябрь г.Казань № 707

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 16 февраль, 84 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 16 февраль, 84 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 8 июнь, 436 нчы; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче; 2023 ел, 18 апрель, 488 нче; 2024 ел, 10 июнь, 414 нче; 2025 ел, 25 гыйнвар, 34 нче; 2025 ел, 17 апрель, 239 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәгечә билгеләнә:

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәге инспекторы», «профконсультант»,

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белгече» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 44 120 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең II категорияле инспекторы», «II категорияле профконсультант», «профориентация буенча белгеч», «гражданнарны социаль һәм психологик адаптацияләү буенча белгеч» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 44 130 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең I категорияле инспекторы», «I категорияле профконсультант» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 44 135 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең өлкән инспекторы» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 44 900 сум күләмендә;

«әйдәүче профконсультант», «халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең әйдәүче инспекторы», «халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең әйдәүче белгече» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр өчен 45 100 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең баш белгече», «халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең баш инспекторы» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр өчен 45 430 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең сектор мөдире» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 45 540 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең бүлек башлыгы урынбасары» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 45 680 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең бүлек башлыгы» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 46 090 сум күләмендә;

«Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Идарә башлыгы урынбасары» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 46 900 сум күләмендә;

«Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Идарә башлыгы» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 54 160 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең департамент башлыгы урынбасары» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 54 530 сум күләмендә;

«халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең департамент башлыгы» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләр өчен 52 270 сум күләмендә.»;

7.2 пунктның беренче абзацында «69 500» саннарын «76 500» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Татарстан Республикасы халкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 010 |

2.2. Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 26 660 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 26 870 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 27 080 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 27 300 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 27 560 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 780 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 28 000 |

| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 29 040 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 29 260 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 29 480 |

2.3. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

2.4. Берьюлы ике эш урынында, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яки башкарылган эш күләменә бәйле рәвештә башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы ике эш урынында эшләү тәртибендә биләгән вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла.»;

2. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин